**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 елның «01» февраленнән № 35

**«Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза бирелә торган мәҗбүри эш төрләрен һәм мәҗбүри эшләр рәвешендәге административ җәза үтәтелә торган оешмалар исемлеген билгеләү турында» 2012 елның 16 ноябрендәге 599 номерлы карарына өстәмәләр кертү хакында»**

Мәҗбүри эш рәвешендә административ җәза билгеләнгән затларны төзәтү, аларда җәмгыять нормаларына, кагыйдәләренә, иҗтимагый яктан файдалы хезмәткә карата хөрмәт уяту максатыннан, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 32.13 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза бирелә торган мәҗбүри эш тө рләрен һәм мәҗбүри эшләр рәвешендәге административ җәза үтәтелә торган ое шмалар исемлеген билгеләү турында» 2012 елның 16 ноябрендәге 599 номерлы карарына түбәндәге эчтәлектәге өстәмәләр кертергә:

- урман кисү урыннарын бүлү (визирлар кисү, делянка баганалары ясау һәм урнаштыру);
- яшь үсентеләрне карау (сирәкләү, чистарту);
- урман фонды территорияләрен төзекләндерү (урман кишәрлекләрен санкцияләнмәгән чүплекләрдән, җитештерү һәм куллану калдыкларыннан чистарту, ял итү урыннары, беседкалар урнаштыру, ауган агачларны чистарту);
- урман культурасы производствосы (урманныКолесов кылычы белән утырту,

урман утыртуда механикалаштырылган аппаратка үсентеләр бирү, агач утырту машинасы артыннан үсентеләрне куеп бару, урман культураларын тулыландыру, урман культуралары мәйданнарын табигый бизәгәндә бүлү баганалары ясау һәм урнаштыру, урман культураларын кул белән агротехник карау);

- авиация һәм җир өсте ысуллары белән зарарлы организмнар учакларын локальләштерү һәм бетерү эшләрен башкарганда агрегатларга эш эретмәләре белән ягулык салу;

- урман янгыннарын җир өсте юлы белән сүндерү (1 нче кушымта).

1. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза бирелә торган мәҗбүри эш төрләрен һәм мәҗбүри эшләр рәвешендәге административ җәза үтәтелә торган оешмалар исемлеген билгеләү турында» 2012 елның 16 ноябрендәге 599 номерлы карарына түбәндәге эчтәлектәге өстәмәләр кертергә:

- «Аксубай урман хуҗалыгы» ДБУ;

- «Биләр урман хуҗалыгы» ДБУ;

- «Зәй урман хуҗалыгы» ДБУ;

- «Кәләй урман хуҗалыгы» ДБУ (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Р. Фасахов**

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2016 елның «01» февраленнән
35 номерлы карарына
1 нче кушымта
**үзгәрешләр:**
2012 елның «16»ноябрендәге
599 номерлы карар

**Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә административ җәза үтәү өчен мәҗбүри эш төрләре**

1. Яңа Чишмә муниципаль районы торак пунктларын төзекләндерү эшләре;
2. Яңа Чишмә муниципаль районы торак пунктларын карап тоту эшләре;
3. Урман кисү урыннарын бүлү (визирлар кисү, делянка баганалары ясау һәм урнаштыру);
4. Яшь үсентеләрне карау (сирәкләү, чистарту);
5. Урман фонды территорияләрен төзекләндерү, урман кишәрлекләрен санкцияләнмәгән җитештерү һәм куллану калдыкларыннан чистарту, ял итү урыннарын тәртипләү, беседкалар урнаштыру, ауган агачларны җыештыру һ. б.);
6. Урман культуралары җитештерү (Колесов җайланмасы белән агач утырту, агач утырту машинасы артыннан үсентеләр биреп бару, урман утырту машинасы артыннан үсентеләр бирү, урман культураларын тулыландыру, урман культуралары мәйданнарын табигый бизәгәндә баганалар әзерләү һәм урнаштыру, урман культураларын агротехник яктан тәрбияләү);
7. Агрегатларны авиация һәм җир өсте ысуллары белән зарарлы организмнар учакларын локальләштерү һәм бетерү эшләрен башкарганда эшче эретмәләр белән тутыру;
8. Урман янгыннарын җир өсте юлы белән сүндерү.

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2016 елның «01» февраленнән
35 номерлы карарына
2 нче кушымта
**үзгәрешләр:**
2012 елның «16» ноябрендәге
599 номерлы карар

**Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза үтәлә торган оешмалар исемлеге**

1. Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләре;
2. ««Яңа Чишмә МПП»ТКХ» ҖЧҖ;

4. «Аксубай урман хуҗалыгы» ДБУ;

5. «Биләр урман хуҗалыгы» ДБУ;

6. «Зәй урман хуҗалыгы» ДБУ;

6. 6. «Кәләй урман хуҗалыгы» ДБУ.